| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Казан ш. № 565-114/кс-2022

2023 елга «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 ноябрендәге 38-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ) өчен әлеге карар кушымтасы нигезендә эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыятенә иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга 2022 елга тарифлар билгеләү хакында» 08.12.2021 №465-132/кс-2021 номерлы карарын 2022 елның 1 декабреннән үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.11.2022 №565-144/кс-2022
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Биектау коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2023 елга эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Биектау муниципаль районы | | | |
| 1 | «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ, технологик яктан үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән берничә система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | |
| 1.1 | Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре кулланучылары | | | |
| 1.1.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 26,04 | | 31,12 |
| 1.1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 21,70 | | 25,93 |
| 1.2 | Дачный авыл җирлеге кулланучылары | | | |
| 1.2.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 35,16 | | 38,81 |
| 1.2.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 29,30 | | 32,34 |
| 1.3 | Чернышевка авыл җирлеге кулланучылары | | | |
| 1.3.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 39,31 | | 57,54 |
| 1.3.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 32,76 | | 47,95 |
| 1.4 | Дөбъяз, Семиозерка һәм Усад авыл җирлекләре кулланучылары | | | |
| 1.4.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | | 34,73 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.4.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | 28,94 | |
| 1.5 | Алан-Бәксәр, Каенлык, Олы Битаман, Олы Кавал, Казаклар, Алат, Суыксу авыл җирлекләре кулланучылары | | | |
| 1.5.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 39,31 | | |
| 1.5.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 32,76 | | |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге